# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Урыс торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**30 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 30 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән халык җыены беркетмәсе төзелде:«Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлегенең Урыс торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертүгә ризамы, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылганнар, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияле һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1. Урыс торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2.Урыс торак пунктында суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

3.Урыс торак пунктында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлеге кертелгән 169 җыенда катнашучылар, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 92 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында катнашучы 92 кеше “РИЗА” позициясе өчен тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Гөлек торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес.

2. Сорау буенча карар кабул ителде дип танырга:«Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлегенең Урыс торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертүгә ризамы, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылганнар, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияле һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1. Урыс торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2.Урыс торак пунктында суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

3.Урыс торак пунктында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

3. Җыен нәтиҗәләрен Урыс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http://menzelinsk.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.http://pravo.tatarstanhttp://menzelinsk.tatarstan.ru

4. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге башлыгы ______________________ И.С. Аксюкова
(имза)